# Киленем – кызым минем

Зөлфия **Җиһан**

Язның соңгы көннәре. Кояш анда-санда калган кар өемнәрен эретеп бетерергә ашыга. Ә карларның тиз генә бирешәсе килми әле, салкынын табигатькә таратып тора.

Зәримә иртә таңнан өй җыештырды, хуш исле, тәмле азыклар әзерләп табын корды. Тормыш иптәше Газинур, Зәримә язып биргән исемлекне тотып, кибеткә чыгып китте. Кичә улы шылтыраткан иде бит: «Бер-ике көнгә кунакка киләбез», – диде. Зәримә алдан алып куелган кучтәнәчкә биреп җибәрәсе бүләкләрен кат-кат барлап чыкты. Улына бик матур түбәтәй алган иде. Түбәтәе булмаганнан түгел, кибеттә йөргәндә күргәч, матурлыгы каршында тыелып кала алмады. Улына бик тә килешәчәк, таман да булачак. Килененә дә шул ук бүлектән искиткеч матур яулык алды. Әлегә намазда булмаса да, киләчәктә улы үзе артыннан ияртер, намазга бастырыр әле дип өметләнә Зәримә. Оныгына да бүләкләрен шул ук мөселман киемнәре бүлегеннән сайлады. Инде оныгын күңеленнән генә киендереп тә карады. Шундый матур, килешле булачак. Өчесенә дә иң матур намазлыклар алган иде. Менә хәзер, балалары килеп җиткәнне көтеп утырганда, барысын да кабаттан барлап чыкты.

Әкрен утка куелган аш, тәмле исләрен таратып, борынны кытыклый, ашыйсыны китерә. Бәлеш тә «пешеп җитәм» дип, «эндәшә башлады». Бая шалтыратып сөйләшкән буенча, ярты сәгатьтән килеп җитәргә тиешләр.

Газинур кайтып керде. Өс киемнәрен салып элгәннән соң, сумкаларын бушата башлады. Ниләр кирәк, барын да алган, әй, булган да инде үзе. Зәримә шунда ук азыкларны урнаштырып куйды.

– Әйдә, җаныем, өстеңне алыштыр, матур итеп каршылыйк әле кадерле кунакларыбызны.

– Хәзер, тиз генә коенып чыгам әле башта.

– Ярый, бар. Киемнәреңне үтүкләп куйган идем, шуларын киярсең, яме.

– Ярый, рәхмәт, матурым.

Газинур юынырга кереп китте. Зәримә, бәлеш белән сөйләшә-сөйләшә, өстенә кургаш ябып куйды.

– Йөзең матур булып кызарган, шулай җитә, көеп китә күрмә, яме. Утыңны да иң кечесенә күчерим әле.

Әзерләп куелган киемнәрен киенеп, аш бүлмәсенә Газинур керде.

– Ай-һай, тәмле исләр чыгаргансың, матурым. Әллә, чәй эчеп алабызмы соң? – Үзем дә шулай уйлап тора идем, чәй кайнаган, әйдә, җаныем, утыр, эчеп алыйк.

Зәримә касәләргә чәй ясый башлады. Үләннәр кушып ясалган чәйнең хуш исе һәрвакыт башларын әйләндереп җибәрә инде Газинурының. Шаяртып, каты итеп чөмереп эчә дә ул гел, икәүләшеп көлешеп алалар. Икесе танышып, очрашып йөри башлаганнан бирле шулай итә ул. Яшь чаклар, «мәңге ач» студентлар: берсе – бишенче, берсе – өченче курста. Зәримәгә тулай торакка тәүге тапкыр кунакка килгәндә, ялгыш каты итеп чөмереп җибәргән иде чәен. Шаркылдап көлешкәннәр иде. Шуннан бирле, икесе генә чәй эчкәндә, шул мизгелне кабатлау – җылы бер гадәткә әйләнде.

Гел яшьлекләрен искә алып торганга әллә, бер дә картаймыйлар кебек үзләре. Гомерләре буена гыйшыклары кимемәгәнгә күрәдер, чит-ятларга да кара- мадылар. Бер-берсен кадерләп-хөрмәтләп, зурлап, яратып яшәделәр. Үзләренең мәхәббәтләрен балаларына да өләштеләр. Гел сөелеп-назланып, дөрес тәрбиядә, шаян сүзләр генә ишетеп үсте Айсылу белән Айнур. Ишектә кыңгырау зыңлады.

Зыңңң...

– Әй, җаныем, балалар килеп житте бит. Әйдә, каршы алыйк.

Өстәл артыннан торып, ишеккә юнәлделәр. Домофон экранында уллары, киленнәре, нәни оныклары күренде. Төймәгә басып, урам капкасын ачканнан соң, ишегалдына каршыларга чыктылар.

Ай-яй, оныклары Зиннур нинди зур булып үскән. Өч яшьлек бит инде хәзер. Киленнәре Гөлнур, һәвакыттагыча чибәр, елмаеп кына тора. Уллары Айнур – гаилә башлыгы буларак, иң арттан, зур сумкалар күтәреп кереп килә.

Зиннур йөгереп килеп әбисенең кочагына чумды. Рәхәтләнеп үбешкән-кочышканнан соң, сикереп төшеп, чын ирләрчә бабасына кул биреп күреште. Бабасы оныгын туйганчы куенында кысып кочаклаганнан соң, җилкәсенә мендереп утыртты. Онык белән күрешүнең беренче өлеше гел шулай башкарыла бу йортта. Гөлнур белән кочаклашып, үбешеп күрештеләр. Айнур әнисен кочаклап үпкәннән соң, әтисе белән каты итеп кул кысыштылар да, жилкәләренә бәргәләшеп алдылар. Өч буын ир-егетләр. Тазалар, көчлеләр. Сөбханаллаһ, карап торулары сокландыргыч. Аның кечкенәсе дә бит әле, бөтен кыланышлары белән әтисен, бабасын кабатлый.

– Әти, мин синнән зур, мин көчле! – дип кычкырды бабасы җилкәсеннән.

– Әлбәттә, көчлесең, улым! Шулай булырга тиеш тә! Бөтенесе рәхәтләнеп көлештеләр.

– Әйдәгез, балалар, әйдә өйгә. Сезне тәмле ашлар, бәлеш көтә. Кода-кодагыйлар ни хәлдә анда, исән-саулар гынамы?

– Яхшы, сәлам әйтеп калдылар сезгә. – Рәхмәт, сәламәт булсыннар! Әйдәгез, керик өйгә, ашап алыйк. Юлдан соң ачыккансыздыр инде.

Урамдагы куанычлы көлешүләр өйгә күчте. Өс киемнәрен салып, кулларын юып алгач, шаулашып-гөрләшеп түгәрәк өстәлне тутырып көлешә-көлешә килеп тә утырдылар. Зәримә алдан әзерләп куелган савытларга аш сала башлады. Шулвакыт киленнең кесә телефоны шалтырады. Гөлнур телефонын алырга сумкасына юнәлде.

– Әйе, тыңлыйм. Тыңлаган саен, киленкәйнең йөзе үзгәрә барды. Аңа карап, башкалар да тып-тын калып, ни булганын аңларга теләп, ашамый көтеп тордылар.

– Әни, әйттем бит инде, без бары тик ике көнгә киттек, ике көннән кайтабыз... Әни, әбиемә дә... Ни булган?.. Больницада?.. Хәле начарайды?.. Ярый... Ярый... Гөлнур телефонын сүндерде, бер сүз эндәшми.

– Кызым, ни булган, йөзең агарды, әллә берәр начар хәбәр булдымы? – дип сорады Зәримә.

Гөлнур эндәшми басып торуын дәвам итте. Айнур килеп, йомшак кына итеп иңеннән кочаклагач кына телгә килде. Йөзе таш курчакныкы кебек усал төс алды һәм, чер-чер килеп, елак тавыш белән, Айнурга гаеп ата башлады.

– Әйттем мин сиңа, бу юлысы кайтмыйк дип. Синең әниең генә кешемени? Минекеләр кеше түгелмени? Менә әбием авырган, үлеп китсә, син генә гаепле буласың, белдеңме...

Айнур аптырап, күзләрен зур ачкан, бер җавап та бирә алмый, өнсез калып, хатынына карап тора. Ә Гөлнур, туктаусыз гаепләр ата. Аның сүзе буенча: мин дә, бер кыенлык та күрми рәхәттә, гомер буе майда йөзгәнмен. Кызыбыз да, гел әзергә-бәзер генә, бер тырышлык та күрсәтми баеп ята. Биатасы – кеше яллап эшләтә. Улым – Айнурым, иркәләнеп кенә үскән. Ә менә Гөлнурны, башыннан сыйпап торучы булмаган. Аның әти-әнисенә әзерләп куймаганнар, алар үзләре эшләп тапкан. Авырлыкта яшәгәннәр, шуңа күрә, бераз җиңелләйтергә генә, кайвакыт исерткеч эчемлекләр кулланалар икән.

Бу гаепләрнең иге-чиге күренми башлагач, Зәримә түзмәде. Килененең кулыннан йомшак кына итеп тотып алды да, аерым бер бүлмәгә таба әйдәде. Гөлнур тартышып тормады, буйсынды. Залда тынлык урнашты. Хәтта өч яшьлек сабый да, хәлне бик яхшы аңлап, беркемгә сорау бирмәде. Бары тик карашы белән өлкәннәрдән җавап эзләде. Әбисе белән әнисе артыннан ишек ябылгач кына: «Әтием» – дип йөгереп килеп, һаман да өнсез катып торган әтисенең көчле, тик кимсетелүдән йомшарып калган аякларыннан кочаклады. Шунда гына, баһадирдай ирегет аңына килеп, сөекле хатыныннан туган яраткан улын – сабыен иелеп кулларына алды.

...Зәримә бик җитди йөз белән килененә карап торды. Бүлмәдә тынлык. Шундый каты тикелди икән бу борынгы телле сәгать. «Кәккүге» дә чыгып, көндезге бер тулганлыкны «әйткәч», айныгандай булып киттеләр. Әни кеше тагын да игътибарлырак итеп карады килененә. «Яшь, сылу хатын. Улымның яратып, гомер юлын бергә үтәргә дип сайлаган тормыш иптәше. Оныгыбызның әнисе. Безнең гаиләгә килеп кергәнсең икән, тәрбияләрбез, Аллаһы боерса», – дип уйлады. Эчендәге шартлардай булган ачуын тыеп, киленен рәнҗетмәскә, йомшак кына сүз башлады.

– Киленкәем, сиңа ни булды? Беренче мәртәбә сине шундый хәлдә күрәм.

Гөлнур шыңшып елый башлады:

– Врёте, Айнур несколько раз рассказал, наверное, уже.

Зәриmәнең тавышы катыланды:

– Юк... Беркайчан да... Алайса, син шушындый күренешне еш оештырасың инде?..

Гөлнур эндәшми, бары тик мышык-мышык шыңшуын дәвам итте.

Зәримә кабат сүз башлады:

– Синең ни хакың бар минем гаиләмне хурларга? Ни беләсең син тормыш турында? Әллә бөтен дөньясы әзер булып торгандыр дип уйлыйсың? Тормышыбызны без институт тулай торагында башладык. Эшли башлагач, коммуналканың бер бүлмәсендә ике бала белән яшәдек. Без кыенлыкларны хәмер белән җиңеләйтмәдек, шуңа күрә бүгенге тормышыбызны кора алдык. Балаларны түгәрәкләрдә йөртергә акча булсын өчен, Газинурым өч-дүрт эштә эшли торган иде. Мин өстәмә дәресләр бирә идем. Минем балаларым иркә кулларда гына үсмәде. Мәктәптә «отлично»га укыдылар, музыка белән дә, спорт белән дә шөгыльләнделәр. Ярышларда беренче урыннарны алып кайта торган иделәр. Акча биреп очындырмадык. Кече яшьтән үк җәйге каникулларда үзләренә велосипед алырлык акча үзләре эшләделәр алар.

Әни кеше, килененең йөзенә туры карап, дәвам итте:

– Кызым биш төрле чит ил теле белә. Син дә бит шундый ук кыз бала. Нигә үзеңнең туган телеңне дә ипи-тозлык кына беләсең?.. Нинди кул эше беләсең син? Минем кызым да, улым да бик күп кул эшләре белә. Хатын-кыз эше, ир-ат эше дип аермадык, икесе дә бөтен эшкә дә өйрәнеп үсте. Аллаһыга шөкер, нәрсәгә тотынсалар, шуны җиренә җиткереп эшләп куялар. Гомер агышы...

Әз генә тынып торганнан соң, кабат сүз башлады:

– Ашарга пешерергә өйрәнәсеңме соң әле, хет? Улым миннән яшерсә дә, ана йөрәге бик сизгер ул. Беләм, гаиләгездә кем ашарга пешергәнен.

Килененә бик җитди итеп карап, каты гына тавыш белән:

– Улыма яңадан авыз ачып бер шакшы сүз әйтәсең булмасын. Моныңчы эндәшми килдем, күрмәмешкә-ишетмәмешкә салыштым. Бүгенге кыланышың чиккә җиткерде. Аңлыйсыңмы, балакаем?.. Алга табан да шулай кылансаң, югалтасың син минем улымны, югалтасың... Безне дә улсыз калдырасың... Ризалыгым юк... Хакың юк синең шулай кыланырга...

Зәримә тынып калды. Бераз тавышын йомшарта төшеп:

– Яратасыз бит сез берберегезне...

Килен каршы бер сүз дәшмәде. Бианасының сөйләгәннәрен башын иеп кенә тыңлап торды.

Зәримә борчылудан калтырый ук башлады. Бик каты ачулы булса да, тавышын күтәрмәде. Тик нык-лы, тигез тавыш белән, киленен әрләде дә, сеңдереп кенә үгет-нәсихәтләрен дә бирде. Килене бианасын беренче мәртәбә күрде бик җитди, каты, күкрәкнең төпкелләреннән чыккан көчле тавыш белән сөйләгәнен. Зәриmәнең буыннары йомшарып киткәндәй булды. Киленеңә сиздерергә ярамый, шуңа күрә урындыкка барып утырды.


/ ФОТО РЕДАКЦИЯ АРХИВЫННАН.

Гөлнур сизенде. Тиккә генә укымаган бит медицина институтында.

– Әнием, гафу ит, рәхим итеп. Яңадан беркайчан да кабатланмас бу кыланышым, – дип бианасын кочаклап, алдына ук килеп утырды. Бианасы да, киленен кочаклап алды, яшьле битләреннән үпте. Чәчләреннән, аркасыннан сыйпап юатты. Килене дә, туган әнисеннән күрмәгән назларны бианасыннан күргәч, бөтенләй үк йомшарды. Үксеп-үксеп, ярсып елады. Кат-кат гафу үтенде. Икәүләшеп елап туйганнан соң, бер-берсенә карап көлешеп алдылар. Керфекләрендәге капкара сөрмәләре битләре буйлап аккан.

Ике буын сылу хатын-кыз: берсе – бианай, берсе – килен, бер-берсен юата-көлешә үзләрен тәртипкә китерделәр. Керфекләрен буяп, чәчләрен тарап бөтенләй үк матурланып алгач, үзләрен түземсезлек белән көтеп торган өч буын яраткан ир-егетләре: берсе – ир-биатай; икенчесе – ул-ир; өченчесе – онык-ул яннарына чыктылар.

Табында ашлар ничек куелган булса, шул килеш тора. Берәү дә кашыкка тотынмаган. Моны күргәч, Гөлнур бик кыенсына башлады. Зәримә аңа үзен гаепле тоярга ирек куймады:

– Киленем – кызым минем, әйдәле, ашны кабат җылытып алыйк. Һәрвакыт җылы булсын ашларыбыз да, өебез дә, мөнәсәбәтләребез дә, Аллаһы боерса!

– Әйе, әнием! Мин хәзер!

Биш минуттан инде, күптән түгел булган тавыш онытылды, һәм башка беркайчан да искә төшерелмәде. Ә ашлар, бәлешләр, үләнле чәйләр, тортлар – искитмәле нык тәмле иде.